ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

07 октябрь, 2019 ел № 33/10

Шәһәр Советының 2018 елның 08 ноябрендәге 27/16 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә шәһәр төзелеше мәсьәләләре буенча иҗтимагый фикер алышу һәм җәмәгать тыңлауларын оештыру һәм үткәрү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

2019 елның 02 августындагы «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 283-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31, 46 маддәләре, шәһәр Уставы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2018 елның 08 ноябрендәге 27/16 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә шәһәр төзелеше мәсьәләләре буенча иҗтимагый фикер алышу һәм җәмәгать тыңлауларын оештыру һәм үткәрү Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 4 пунктның 3 пунктын түбәндегә эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Аерым өлешләрен раслау юлы белән территорияне планлаштыру проектларына һәм (яки) территорияне межалау проектларына үзгәрешләр кертелгән очракта, иҗтимагый фикер алышу яки җәмәгать тыңлаулары расланучы өлешләргә карата үткәрелә.»;

2) 28 пунктның 2 пунктчасында «ике атнадан ким һәм дүрт айдан артык булмаган» сүзләрен «бер айдан ким һәм өч айдан артык булмаган» сүзләренә алыштырырга.

3. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ